РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
КУКМОРСКИЙ МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН
СОВЕТ САРДЕКБАШСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
КУКМАРА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
СӘРДЕКБАШ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

**422126, Яңа Сәрдек авылы, Үзәк урам, 45. тел./факс: (884364) 25-0-43** e-mail: Sard.Kuk@tatar.ru,

# КАРАР

22 март, 2024 ел №15

Кукмара муниципаль районы Сәрдекбаш авыл җирлегенең Бакчасарай поселогы торак пунктында «Кукмара муниципаль районы Сәрдекбаш авыл җирлегенең Бакчасарай поселогы торак пунктында үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» 2023 елның 29 ноябрендәге 1 номерлы Бакчасарай поселогы гражданнар җыены карарына үзгәрешләр кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыены үткәрүне билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Сәрдекбаш авыл җирлеге Уставы нигезендә, Сәрдекбаш авыл җирлеге Советы

КАРАР БИРДЕ:

1. 2024 елның 07 апреленә 15 сәгать 00 минутка «Кукмара муниципаль районы Сәрдекбаш авыл җирлегенең Бакчасарай поселогында үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» 2023 елның 29 ноябрендәге 1 номерлы Бакчасарай поселогы гражданнар җыены карарына үзгәрешләр кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыены үткәрүне билгеләргә.

2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«Сез Кукмара муниципаль районы Сәрдекбаш авыл җирлегенең Бакчасарай поселогында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында 2023 елның 29 ноябрендәге 1 номерлы карарына түбәндәге мәсьәлә буенча үзгәрешләр кертүгә ризамы: «Сез 2024 елда Кукмара муниципаль районының Сәрдекбаш авыл җирлеге Бакчасарай поселогы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, 1 төркем инвалидларыннан; көндезге уку формасы буенча укучы укучылар һәм студентлардан (курсантлардан); 85 яшькә җиткән һәм аннан өлкәнрәк затлардан,Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә сроклы хәрби хезмәткә чакырылган затлардан; Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә хәрби хезмәткә чакырылган затлар һәм аларның гаилә

әгъзаларыннан кала, 3000 сум күләмендә үзара салым кертү белән һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

- Бакчасарай поселогында юлларга асфальт җәю, вак таш салып ремонтлау һәм карап тоту; проект-смета документлары һәм проектларга экспертиза; техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру;
- Бакчасарай поселогында янгын куркынычсызлыгының беренчел чараларын тәэмин итү, янгын гидрантларын урнаштыру, ремонтлау һәм карап тоту, янгын инвентаре сатып алу, янгын куркынычсызлыгы чараларын тәэмин итү өчен махсус машина сатып алу һәм карап тоту, янгын сүндерү техникасын тотуга чыгымнар; проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру;
- Бакчасарай поселогы территориясен төзекләндерү өчен трактор сатып алу һәм тоту, тракторны тоту чыгымнары; проект-смета документациясен эшләү һәм технадзорны гамәлгә ашыру;
- Бакчасарай поселогының урам юл челтәрен карап тоту;
- Бакчасарай поселогындагы зиратны коймалау һәм карап тоту , зират өчен җиһазлар һәм инвентарь сатып алу; проект-смета документларын эшләү;
- Бакчасарай поселогында урам яктыртуны карап тоту; урам яктырткычларын сатып алу һәм ремонтлау; тимер-бетон терәкләрне монтажлау; проект-смета документларын эшләү;
- Бакчасарай поселогы территориясен төзекләндерү; проект-смета документларын эшләү;
- ял итү зоналарын булдыру , төзекләндерү һәм карап тоту, спорт һәм балалар уен мәйданчыклары һәм инвентарьлар сатып алу; проект-смета документларын эшләү;
- Бакчасарай поселогында автомобиль күпере төзү һәм ремонтлау; проект-смета документларын эшләү;
- Бакчасарай поселогында коеларны төзү, ремонтлау һәм аларга якын территорияне төзекләндерү; проект-смета документларын эшләү;
Бакчасарай поселогын су белән тәэмин итү челтәрен ремонтлау һәм тоту;
проект-смета документларын эшләү;

2023 елның 29 ноябрендәге 1 номерлы карарында күрсәтелгән эш төрләрен үзгәртү өлешендә түбәндәге эшләр белән:

- **торак пункт чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту**(юлларга вак таш һәм асфальт салу, карап тоту, ремонтлау һәм төзекләндерү, проект-смета документлары һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру, юлларны төзү, карап тоту һәм төзекләндерү буенча башка эш төрләре); (Бакчасарай поселогында урам-юл челтәрен карап тоту, ягулык-майлау материаллары һәм запас

частьләр сатып алу, проект-смета документлары, юлларны карап тоту буенча башка эш төрләре);

- **торак пункт территориясен төзекләндерү** (Бакчасарай торак пунктында агачларны кисү, - ял итү зоналарын булдыру , төзекләндерү һәм карап тоту, спорт һәм балалар уен мәйданчыклары һәм инвентарьлар сатып алу; бөя яр буйларын ныгыту; проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру, җирлек территориясен төзекләндерү буенча башка эш төрләре);

- **традицион күмү урыннарын ремонтлау, коймалар төзү, төзекләндерү**;Бакчасрай поселогы зираты территориясен карап тоту һәм төзекләндерү, инвентарь сатып алу, проект-смета документларын эшләү, зират территориясен төзекләндерү һәм карап тоту буенча башка эш төрләре); (Бакчасарай поселогы зиратында агачларны кисү, проект-смета документлары, техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру, зиратны төзекләндерү буенча башка эш төрләре);

- **су белән тәэмин итү һәм су агызу системаларын, су суырту манараларын, скважиналарны һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортлауны һәм халыкка су бирүне тәэмин итә торган инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау** (су белән тәэмин итү челтәрләрен, су саклау зоналарын һәм су суырту манараларын карап тоту, ремонтлау һәм төзекләндерү, артезиан скважиналары өчен насослар сатып алу һәм урнаштыру, проект-смета документлары, техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру, су белән тәэмин итүне, су саклау зоналарын һәм су суырту манараларын карап тоту буенча башка эш төрләре;

- **тышкы урам яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм аларга бирелгән башка подстанцияләрне һәм мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка җиһазларны ремонтлау** (урам яктыртуны карап тоту, комплектлау материаллары сатып алу һәм урнаштыру, урамнарны яктыртуны карап тоту буенча башка эш төрләре; проект-смета документлары, техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру, урам электр челтәрен ясау, карап тоту буенча башка эш төрләре);

- **янгын куркынычсызлыгының беренчел чараларын тәэмин итү** (Бакчасарай поселогында янгын куркынычсызлыгының беренчел чараларын тәэмин итү, янгын гидрантларын урнаштыру, ремонтлау һәм карап тоту, янгын инвентаре сатып алу, ДЕПОны ремонтлау, янгын куркынычсызлыгы чараларын тәэмин итү өчен махсус машина сатып алу һәм карап тоту, янгын сүндерү техникасын тотуга чыгымнар; проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру);

**- Бакчасарай поселогында тукталыш комплексларын ремонтлау, сатып алу һәм урнаштыру**

«РИЗА» «КАРШЫ»

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Сәрдекбаш авыл җирлеге Уставында билгеләнгән тәртиптә бастырып чыгарырга, шулай ук аны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

Җирлек башлыгы: И.М. Набиев